ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«5» июнь 2020 ел № 433

**Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләрне, нормативларны, сынауларны (тестларны) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәге төзү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 11 июнендәге 540 номерлы карары белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы турындагы Нигезләмәнең 26 пункты, Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының Россия Федерациясе Юстиция Министрлыгында 2015 елның 26 февралендә 36215 номеры белән теркәлгән «Физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә сынаулар (тестлар) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәкләре булдыру тәртибен, нормативларны, таләпләрне һәм алар турында нигезләмәләрне раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 954/1 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 4 сентябрендәге 1763-р номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә ашыру хакында" карары нигезендә Арча район башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы «Арча» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләрне, нормативларны, сынауларны (тестларны) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәге вәкаләтләрен бирергә.

2. «Арча» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры Р.Р. Йосыповны Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләрне, нормативларны, сынауларны (тестларны) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәге җитәкчесе итеп билгеләргә.

3. Физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен

бәяләүгә таләпләрне, нормативларны, сынауларны (тестларны) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәге (алга таба – тестлар үткәрү үзәге) турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

4. "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү буенча координация советы составын расларга (2 нче кушымта).

5. "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын кабул итү буенча хөкемдарлар комиссиясе составын расларга (3 нче кушымта).

6. Гамәлдәге спорт объектлары һәм белем бирү оешмалары базасында тест үткәрү урыннарын расларга (4 нче кушымта).

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Арча муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (Т.В. Баһаутдиновка) физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүдә нормативларны, таләпләрне үтәү буенча чаралар үткәрү урыннарында медицина персоналының дежур торуын оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

8. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләрне, нормативларны, сынауларны (тестларны) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәге төзү турында" 2015 елның 5 августындагы 759 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
«5» июнь 2020 ел, №433
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләрне, нормативларны, сынауларны (тестларны) үтәү буенча тестлар үткәрү үзәге турында**
**Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 11 июнендәге 540 номерлы карары белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура - спорт комплексы турындагы Нигезләмәнең 26 пункты нигезендә эшләнде.

1.2. Нигезләмә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының (алга таба – ГТО комплексы) нормативларын үтәү һәм белем дәрәҗәсен бәяләү нәтиҗәләре нигезендә халыкның физик әзерлегенең гомуми дәрәҗәсенә тестлар үткәрүне гамәлгә ашыра торган тестлар үткәрү үзәге оештыру һәм эшчәнлеге тәртибен билгели.

2. Тестлар үткәрү үзәгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Тестлар үткәрү үзәге эшчәнлегенең төп максаты – Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының 2014 елның 8 июлендәге 575 номерлы боерыгы белән расланган ГТО комплексы нормативларын (алга таба-дәүләт таләпләре) үтәгәндә, гражданнарның физик әзерлек дәрәҗәсенә карата дәүләт таләпләренең (алга таба-дәүләт таләпләре) үтәлешен бәяләүне гамәлгә ашыру.

2.2. Тест үткәрү үзәгенең бурычлары:

2.2.1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә карата таләпләрне, сынаулар (тестлар) төрләрен, нормативларны үтәүгә әзерлек буенча консультация бирү һәм методик ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудыру;

2.2.2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләү нормативларын, таләпләрне үтәү буенча тестлар үткәрүне оештыру.

2.3. Тест үткәрү үзәге эшчәнлегенең төп төрләре:

2.3.1. Халыкта физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә, физик камилләшүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга сынаулар (тестларны) һәм ГТО комплексы нормативларын үтәү чараларында катнашуны популярлаштыруга юнәлтелгән пропаганда һәм мәгълүмати эш алып бару.

2.3.2. Халыкка, спорт, иҗтимагый һәм башка оешмаларга дәүләт таләпләрен үтәү өчен шартлар тудыру һәм методик ярдәм күрсәтү.

2.3.3. Россия Спорт Министрлыгының 2014 елның 29 августындагы 739 номерлы боерыгы белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын оештыру һәм үткәрү Тәртибе кысаларында тест үткәрүне гамәлгә ашыру.

2.3.4. Тест уздыру урыннарында күрсәтелгән тест нәтиҗәләрен исәпкә алып бару, ГТО комплексы нормативларын үтәү беркетмәләрен әзерләү, әлеге беркетмәләрне тестларны үткәрүне оештыру һәм үткәрү Тәртибе таләпләре нигезендә гомумиләштерү өчен тапшыруны тәэмин итү.

2.3.5. Тестлар үткәрүдә катнашучылар турында мәгълүматларны, тест нәтиҗәләрен һәм җыелма беркетмә мәгълүматларын ГТО комплексының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертү.

2.3.6. Төбәкара, Бөтенроссия һәм халыкара физкультура һәм спорт чараларының бердәм календарь планына, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең физкультура чаралары һәм спорт чараларының календарь планнарына кертелгән ГТО комплексы чараларын оештыруда катнашу.

2.3.7. ГТО комплексын гамәлгә кертүдә ГТО комплексы чараларын уздыру мәсьәләләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итү.

2.3.8. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булганда, ГТО комплексы буенча физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрнең квалификациясен күтәрүне оештыруда катнашу.

2.3.9. Халыкка тестлар үткәрү буенча хөкемдарлык итүне тәэмин итү.

2.4. Тестлар үткәрүне оештыру өчен Арча муниципаль районында тест үткәрү үзәгенең күчмә комиссиясе оештырыла.

2.5. Тестлар үткәрү билгеләнгән таләпләргә туры килә торган спорт объектларында, шул исәптән файдалану куркыныч булмаган урыннарда гына оештырыла.

## 3. Якларның үзара хезмәттәшлеге

3.1. Тест үткәрү үзәгенең хокуклары:

3.1.1. Россия Федерациясе законнары һәм тестлар үткәрүне оештыру һәм үткәрү Тәртибе нигезендә тестларда катнашырга рөхсәт итү һәм катнашучыларга ГТО комплексының сынау төрләрен (тестларны) үтәүгә рөхсәт бирүдән баш тарту.

3.1.2.Тестлар үткәрүдә катнашучылардан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан үзенең эшчәнлеге өчен кирәкле мәгълүматны соратып алу.

3.1.3. ГТО комплексының дәүләт таләпләре структурасын һәм эчтәлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү.

3.1.4. Гражданнарга тестлар үткәрү процессын оештыру өчен волонтерлар җәлеп итү.

3.2. Тест үткәрү үзәгенең бурычлары:

3.2.1.Тестлар үткәрүне оештыру һәм үткәрү Тәртибен, спорт һәм физкультура чараларын үткәрүне регламентлаучы башка норматив-хокукый актлар таләпләрен үтәү.

3.2.2. ГТО комплексы кысаларында тест һәм башка чаралар үткәргәндә, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру өчен шартлар тудыру.

## 4. Матди-техник тәэмин ителеш

4.1. Тест үткәрү үзәге тестларда катнашучыларны тест үткәрү өчен кирәкле спорт җиһазлары һәм инвентарь белән матди-техник яктан тәэмин итә.

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
«5» июня 2020 ел, № 433
карарына 2 нче кушымта

Арча муниципаль районында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО)
Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә кертү буенча
координация советы утырышы
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Мөхетдинов Р.Р. | Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Габделгазизов И.Н. | Координация советы рәисе урынбасары, Арча муниципаль районының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| | Координация советы әгъзалары: |
| Галимова С.П. | "ТР Арча муниципаль районы ФБП " МКУ җитәкчесе |
| Баһаветдинов Т.В. | Арча үзәк район хастаханәсе баш табибы ( килешү буенча); |
| Баһавиев А.Р. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Габдрахманова Г.Ә. | Арча район Советының оештыру бүлеге башлыгы; |
| Мөхәммәдияров Р.Д. | Арча муниципаль районы "Мәгариф идарәсе" МУ башлыгы; |
| Мөхәммәтшина А.Т. | Арча муниципаль районы "Мәдәният идарәсе" МУ башлыгы; |
| Борһанов А.А. | ТР Арча һәм Әтнә районнары буенча хәрби комиссары (килешү буенча); |
| Алеев Р. Р. | ТР ДОСААФ Арча МБ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Мусина Л.Н. | Г. Тукай исемендәге АПК директоры (килешү буенча); |
| Завялова Л.Н. | Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиясе баш белгече; |
| Җәләлетдинов Т.Т. | "Бердәм Россия" партиясенең Арча җирле бүлекчәсе башкарма секретаре (килешү буенча); |

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
«5» июнь 2020ел, № 433
карарына 3 нче кушымта

Арча муниципаль районында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО)
Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын кабул итү буенча
хөкемдарлар комиссиясе
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Габделгазизов И.Н. | хөкемдарлар комиссиясе рәисе, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Хисмәтова Л.Г. | хөкемдарлар комиссиясе рәисе урынбасары, "Арча" спорт мәктәбенең укыту эшләре буенча директор урынбасары (килешү буенча); |
| Зәйнуллин И.М. | хөкемдарлар комиссиясе баш секретаре, «Форпост» М(С) ФОООП МБУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хөкемдарлар комиссиясе әгъзалары: | |
| Йосыпов Р.Р. | "Арча" спорт мәктәбе директоры (килешү буенча); |
| Шакиров И.М. | "Арча Арена" спорт мәктәбе" МБУ директоры (килешү буенча); |
| Хәбибуллин И.А. | "Мәгариф идарәсе" МУ методисты (килешү буенча); |
| Борһанова Ф.Ш. | "Арча" спорт мәктәбе инструктор-методисты (килешү буенча); |
| Сәгыйтов З.В. | "Г.Тукай исемендәге АПК" физик тәрбия җитәкчесе (килешү буенча); |
| Гыйләҗиев Р.Н. | "Г.Тукай исемендәге АПК» физик культура укытучысы (килешү буенча); |
| Гарифуллин Г.В. | "Г.Тукай исемендәге АПК» физик культура укытучысы (килешү буенча); |
| Зарипов Р.З. | "Г.Тукай исемендәге АПК» физик культура укытучысы (килешү буенча); |
| Галимҗанов Ф.М. | "Г.Тукай исемендәге АПК» физик культура укытучысы (килешү буенча); |
| Җамалиева З.В. | Татарстан Республикасы "ГТО" РОО белгече |
| Сәләхов А.Ә. | Арчаның 1нче урта мәктәбе физкультура укытучысы. (килешү буенча); |
| Абдрахманов И.Х. | Арчаның 5нче гимназиясе физкультура укытучысы (килешү буенча); |
| Әхмәдуллина М.Р. | Арчаның 2нче урта мәктәбе физкультура укытучысы (килешү буенча); |
| Гәрәев Б.Р. | Арчаның 7нче урта мәктәбе физкультура укытучысы |

| | |
|---|---|
| | (килешү буенча); |
| Нәбиуллин Р.Р. | Арчаның 6 нчы мәктәбе физкультура укытучысы (килешү буенча); |
| Насыйбуллин Р.Р. | "Арча" спорт мәктәбе тренер-укытучысы (килешү буенча); |
| Мозаффарова Г.М. | "Арча" спорт мәктәбе тренер-укытучысы (килешү буенча); |
| Лотфуллин Т.А. | "Арча" спорт мәктәбе тренер-укытучысы (килешү буенча); |
| Мөхәммәтшин Ф.Ф. | "Арча" спорт мәктәбе тренер-укытучысы (килешү буенча); |
| Абдрахманов И.Ф. | "Арча" спорт мәктәбе тренер-укытучысы (килешү буенча); |
| Зарипов Ф.В. | "Арча" спорт мәктәбе тренер-укытучысы (килешү буенча); |

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
«5» июнь 2020ел, № 433
карарына 4 нче кушымта

Арча муниципаль районының гамәлдәге спорт объектлары һәм белем бирү оешмалары базасында тест үткәрү урыннары
Исемлеге

| № | Объектның атамасы | Спорт төрләре |
|---|---|---|
| 1 | Үзәк стадион<br>(Тау асты ур., 1а) | - 30 м, 60 м, 100 м, 1000 м, 1500 м, 2000 м, 3000 м га йөгерү;<br>- биек турникта (тәбәнәк турникта) тартылу (тапкыр);<br>- 16 кг лы гер күтәрү (тапкыр);<br>- ятып кулларны бөгү-турайту (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкта);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- 150 гр.лы туп ыргыту. 500 гр., 700 гр. лы спорт снаряды ыргыту, теннис тубы ыргыту (дистанция 6 м, тапкыр);<br>-1 км, 2 км, 3 км, 4км га катнаш хәрәкәт итү;<br>-2 км, 3 км, 4 км га скандинавия йөреше белән йөрү;<br>- гимнастик эскәмиядә аягүрә басып, идәнгә басып, алга авышу;<br>- ике аяк белән этенеп, урыннан озынлыкка сикерү;<br>- йөгереп килеп озынлыкка сикерү;<br>- 3 км, 4 км,5км га чаңгыда йөрү |
| 2 | "Г.Тукай исемендәге АПК"<br>(Вагыйзовлар ур., 14, директоры-Мусина Л.Н.) | - 30 м, 60 м, 100 м, 1000 м, 1500 м, 2000 м, 3000 м га йөгерү;<br>- гер күтәрү;<br>- биек турникта (тәбәнәк турникта) тартылу (тапкыр);<br>- ятып кулларны бөгү-турайту (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкта);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- 150 гр. лы туп ыргыту. 500 гр., 700 гр лы спорт снаряды ыргыту<br>- биек турникта (тәбәнәк турникта) тартылу (тапкыр);<br>- 16 кг лы гер күтәрү (тапкыр);<br>- гимнастик эскәмиядә аягүрә басып, идәнгә басып, алга авышу;<br>- ике аяк белән этенеп, урыннан озынлыкка сикерү;<br>- йөгереп килеп озынлыкка сикерү;<br>- пневматик винтовкадан өстәл яки стойкага таянып утырып яки басып ату (5 м дистанция). |
| 3 | Арчаның 1нче мәктәбе<br>(Мәктәп ур., 2, директоры-Сафина Э. Н) | - 30 м, 60 м,100 м, 1000 м, 1500 м, 2000 м, 3000 м га йөгерү;<br>- биек турникта (тәбәнәк турникта) тартылу (тапкыр); |

| | | |
|---|---|---|
| | | - 16 кг лы гер күтәрү (тапкыр);<br>- ятып кулларны бөгү-турайту (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкның утыргычында);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- 150 гр.лы туп ыргыту. 500 гр., 700 гр. лы спорт снаряды ыргыту, теннис тубы ыргыту (дистанция 6 м, тапкыр);<br>- гимнастик эскәмиядә аягүрә басып, идәнгә басып, алга авышу<br>- йөгереп килеп озынлыкка сикерү |
| 4 | АРЧАНЫҢ ИКЕНЧЕ МӘКТӘБЕ<br><br>(Күпер ур., 15, директоры-Гиниатуллина Г. Г.) | - 30 м, 60 м,100 м, 1000 м, 1500 м, 2000 м, 3000 м йөгерү;<br>- биек турникта (тәбәнәк турникта) тартылу (тапкыр);<br>- 16 кг лы гер күтәрү (тапкыр);<br>- ятып кулларны бөгү-турайту, (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкта);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- 150 гр.лы туп ыргыту. 500 гр., 700 гр. лы спорт снаряды ыргыту, теннис тубы ыргыту (дистанция 6 м, тапкыр);<br>- гимнастик эскәмиядә аягүрә басып, идәнгә басып, алга авышу<br>- йөгереп килеп озынлыкка сикерү. |
| 5 | Арчаның 5нче гимназиясе<br>(Зур ур., 77, директоры-Хәкимуллин Ф. Х.) | - ятып кулларны бөгү-турайту (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкның утыргычында);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- 150 гр. лы туп ыргыту. 500 гр., 700 гр. лы спорт снаряды ыргыту, теннис тубы ыргыту (дистанция 6 м, тапкыр);<br>- гимнастик эскәмиядә аягүрә басып, идәнгә басып, алга авышу<br>- йөгереп килеп озынлыкка сикерү;<br>- ятып кулларны бөгү-турайту, (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкның утыргычында);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- пневматик винтовкадан өстәл яки стойкага таянып утырып яки басып ату (5 м дистанция). |
| 5 | "Арча" спорт мәктәбе<br>(Интернационал ур., 16, директоры-Йосыпов Р.Р. | -йөзү;<br>- биек турникта (тәбәнәк турникта) тартылу (тапкыр);<br>- 16 кг лы гер күтәрү (тапкыр);<br>- ятып кулларны бөгү-турайту (идәндә, гимнастика эскәмиясендә, урындыкның утыргычында);<br>- аркада яткан килеш гәүдәне күтәрү (1 минут эчендә бер тапкыр, вакытны исәпләмичә);<br>- йөгереп килеп озынлыкка сикерү;<br>- гимнастик эскәмиядә аягүрә басып, идәнгә басып, алга авышу;<br>- гер күтәрү. |